ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 гыйнвар 2026ел № 04

Башкарма комитетның «Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2025 елның 31 октябрендәге 8919 номерлы Карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 статьясының 3, 4 өлешләре, 158 статьясының 4 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы Карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең 35 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләрнең һәм эшләрнең минималь исемлеге, аларны күрсәтү һәм башкару тәртибе турында» 2013 елның 3 апрелендәге 290 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар һәм (яки) торак урынны карап тотуга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында» 2025 елның

31 октябрендәге 8919 номерлы Карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

| № т/б | Түләү исеме | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | 01.11.2025 елдан хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 4. | Төзелеш корылмаларына һәм биналарның инженерлык системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, шул исәптән: | | |
| 4.1. | торак биналарны агымдагы ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м | 4,97 |

2) Искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Искәрмә:

* - Түләүнең туры килү коэффициентын исәпкә алып.

- Тарифлар өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алып билгеләнгән.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов